СОВЕТ НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«23» июль 2024 ел № 108

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 декабрендәге 119 номерлы “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башлыгы, Норма авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү тәртибе турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2024 елның 4 июнендәге 252 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына Контроль-хисап палатасы рәисенә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен акчалата бүләкләү турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы (13.10.2022 № 144 үзгәрешләр белән) карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Норма авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 декабрендәге 119 номерлы “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башлыгы, Норма авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү тәртибе турында”гы (25.05.2023 № 80 үзгәрешләр белән) карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 2 пунктчасында «12688» санын «13323» санына алмаштырырга;

1.2. Норма авыл җирлеге башлыгының, Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы Тәртибенең 1 пунктында «19039» санын «19991» санына алмаштырырга;

1.3. Норма авыл җирлеге башлыгынын, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы Тәртибенең 2 пунктында «10,36» санын «14,12» санына алмаштырырга;

1.4. 3 нче кушымтаның 6 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов